| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ<br>«ГОРОД ЧИСТОПОЛЬ»<br>ЧИСТОПОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ<br>ГОРОДСКОЙ СОВЕТ** | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>**ЧИСТАЙ<br>ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ** |
|---|---|

***Решение*** ***Карар***

**2022 елның 12 мае** **Чистай шәһәре** **№14/7**

Татарстан Республикасы Чистай
муниципаль районы Чистай шәһәре
Советының «Ачык тыңлауларны
(җәмәгать фикер алышуларын) оештыру
һәм үткәрү тәртибе турында»
2018 елның 27 июнендәге 26/2 номерлы
карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәре Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәре Советының «Ачык тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 27 июнендәге 26/2 номерлы карары белән расланган (Чистай шәһәре Советының 2019 елның 28 февралендәге 32/2 номерлы карары редакциясендә) ачык тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 6 статьяның 2 пунктындагы икенче абзацында «проект, мәсьәлә» сүзләреннән соң «иҗтимагый фикер алышуларны яисә ачык тыңлауларны оештыручы адресына электрон документ рәвешендә яисә» сүзләрен өстәргә;

1.2. 12 статьяның 3 абзацына «, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 28 статьясындагы 3.1 өлешендә билгеләнгән очраклардан тыш. Территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителү сәбәпле, җирлекнең генераль планына үзгәрешләр әзерләнгән очракта, җәмәгатьчелек фикер алышулары яки ачык тыңлаулар территория чикләрендә үткәрелергә мөмкин, аңа карата территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән очракта.» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Чистай шәһәре Советының законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә О.В. Добронравовага йөкләргә.

Чистай муниципаль районы
Чистай шәһәре башлыгы Д.А. Иванов